ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
III чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-18-57, факс 3-15-05.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
III созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-18-57, факс 3-15-05.

**КАРАР**
от 20 февраля 2019 года

**РЕШЕНИЕ**
№36-01

**О социально-экономическом развитии Актанышского муниципального района в 2018 году и задачах на 2019 год**

Заслушав доклад Главы Актанышского муниципального района Фаттахова Э.Н. о социально-экономическом развитии Актанышского муниципального района в 2018 году и задачах на 2019 год, Совет Актанышского муниципального района РЕШИЛ:

1. Отчет Главы Актанышского муниципального района Фаттахова Э.Н. о социально-экономическом развитии Актанышского муниципального района в 2018 году и задачах на 2019 год принять к сведению (прилагается).
2. Всем руководителям предприятий, организаций, учреждений независимо от форм собственности, органам местного самоуправления Актанышского муниципального района руководствоваться в своей деятельности настоящим решением, активно содействовать в реализации поставленных задач и обеспечении исполнения настоящего решения.
3. Контроль за исполнением настоящего решения возложить на заместителя Главы Актанышского муниципального района Р.Ф.Галимянову.

Председатель Совета
Актанышского муниципального района Э.Н.Фаттахов

**Хөрмәтле депутатлар!**

**Хөрмәтле Марат Готович!**

**Хөрмәтле утырышта катнашучылар!**

Узган 2018 ел күп кенә сәяси, истәлекле, тарихи вакыйгаларга һәм күренекле даталарга бай булды.

Март аенда узган Россия Федерациясе Президентын сайлауда, районыбыз сайлаучылары югары дәрәҗәдә оешканлык күрсәтеп, сайлауларда актив катнашып, үзләренең тавышларын В.В.Путин кандидатурасына бирделәр.

Районыбызда 98% татарлар яшәвен искә алып, узган ел район Сабантуен да мөмкин кадәр мөселман гореф-гадәтләрен кертеп, чын татар Сабантуе үткәрү буенча беренче адымнар ясадык. Шулай ук "Актаныш гармуннары" һәм Әлфия Авзалова исемендәге беренче төбәкара фестивальләр үткәрү дә районыбызның республика районнары арасында гына түгел, Рәсәйнең башка регионнарына да танылырга һәм яшәү рәвешен күрсәтергә мөмкинлек бирде.

Узган елны отчет куйганда мин әйтеп киткән идем "Мин әле 2017 елның декабрь аенда гына кайтып сезнең белән бергә эшли башладым. Шуңа күрә минем чыгышымның төп максаты 2017 елда эшләнгән эшләр турында гына сөйләү түгел, ә һәр тармакта хәлнең торышын анализлап алга таба бурычлар һәм ирешәсе максатлар турында күбрәк булыр" дип. Менә бер ел үтеп тә китте, 2018 нче елда башкарылган эшләр, ирешелгән уңышлар, социаль-икътисадый күрсәткечләр минем өчен киләчәккә таяну ноктасы (точка отсчета) булып тора. Алга таба, халык хуҗалыгының барлык тармакларының да динамикалы үсеш юлыннан баруын тәэмин итеп, халыкның яшәү дәрәҗәсен яхшырту максатыннан, районыбыз республикада алдынгы районнарның берсе булырга тиеш дигән бурыч куябыз һәм моның өчен безнең бөтен мөмкинлекләребез дә бар.

Әлбәттә, нинди генә максатлар куйсак та, нинди генә программаларны тормышка ашырырга хыяллансак та, иң беренче чиратта кеше факторы килеп баса. Безнең барлык уй-хыялларыбызны да район халкы тормышка ашыра, шуңа күрә дә районыбызның зур байлыгы булып аның халкы тора.

## Демография

Сүземне демографик хәлгә анализ ясаудан башлыйм. Статистик мәгълүмәтләр буенча, 2019 елның 1 нче январенә районда 30165 кеше яши.

Халкыбызнын 20% балалар(6167), 30% пенсионерлар.(9110) һәм 49,3% эш көчендәге кешеләр(14882), Шуларның 8084е икътисадның торле тармакларында район оешмаларында хезмәт куя, 550 шәхси эшмәкәр уз-узләрен эш белән тәэмин итәләр, 3125 кеше районнан читтә эшли ш.э. 2023 районда пропискада торып

читтә яшәп эшлиләр, ә 1102 кеше районда яшәп вахта методы белән читтә эшлиләр, 686кеше- торле пенсия алучылар.

2018 елда районыбызда 278 бала туган, бу узган ел белән чагыштырганда 8 балага кубрәк. Туучылар саны 1000 кешегә исәпләгәндә 9,2 тәшкил итте, 2017 ел белән чагыштырганда 0,3ка күбрәк. Шул ук Минзәлә районнында 8,4кенә, Тукайда 8,9 бездән тубән, Сарманда 9,3. Мослимдә 1000кешегә исәпләгәндә 10,9 бала туган.

2018 елда район буенча гомуми үлүчеләр саны 411 кеше 2017 елга караганда 63 кешегә кимрәк (2017 ел- 474 кеше). Үлем төрләрен анализлап караганда- 162се йөрәк һәм кан тамыры авыруыннан, 55 онкологик, тышкы сэбэплэр аркасында улучелэр саны 20.

2018 елда гомуми улем 1 мен кешегэ исәпләгәндә -13.7. Курше районнар белән чагыштырганда Минзэлэдэ 17,3 Мослимдә -16,7 Сарманда 14,6, Тукайда – 11,9. Ә республика курсэткече 11,5кә җитуне максат итеп куябыз.

Табигый үсеш күрсәткечләре, кызганычка каршы сөендерерлек түгел.

Район халкының уртача гомер озынлыгы 2018 елда 74,6 яшь тәшкил итте, ир – атлар – 68,0, хатын-кызлар-79,8 яшь. 2017 елда гомер озынлыгы 74,0, ир – атлар - 67,0, хатын-кызлар-78,5ел иде. Район халкының гомер озынлыгының арту тенденциясе бар.

Татарстан Республикасының Усеш Стратегиясенең топ максаты 2030 елга Татарстан Республикасы халкының уртача гомер озынлыгын 80 яшькә җиткерү.

Демографик ситуация дәүләтебезнен дә төп сәясәтенә әверелеп бара. Узган елда Россия Президенты тәкъдим иткән чаралар да үз чиратында балалар тууга уңай йогынты ясар дип ышанасы килә. Районда “Ныклы гаилә” проекты кысаларында ай саен район башлыгы, авыл җирлекләре башлыклары, мәктәп директорлары, фельдшерлар, табиблар, полиция хеметкәрләре, районның социаль олкәсендә хезмәт куючылар катнашында “25 форма” киңәшмәсе уза. Әлеге киңәшмәдә райондашларыбызның яшәү шартлары, эчүче гаиләләр, улучеләрнең сәбәпләре анализлана. Әлеге эшчәнлек буенча хәр бер авыл җирлегенә урыннар чыгарыла, иң яхшы нәтиҗәгә ирешкән авыл башлыгы кучмә пар кугәрченнәр белән бирелә.

**Хезмәт хакы һәм җан башына алган керем**

2018 нче елда районның динамикалы үсеше һәм хезмәт хакын күтәрү буенча

артты һәм 27455 сум тәшкил итте. Тармаклап карасак: файдалы казылмалар чыгару олкәсендә(нефть) -51 мең сум, район бюджет оешмаларында – 25387 сум, авыл хужалыгы оешмаларында 22 мең сум, тозелеш оешмаларында-15225сум, кече эшмәкәрлектә 16640сум тәшкил итте. Хезмәт хакын туләү буенча районда бурычлы оешмалар юк.

Уртача пенсия куләме районда 12883 сум, узган елга караганда 9% арткан.

Хезмәт хакының һәм пенсия күләменең артуы җан башына акча керемнәренең үсешен 5,8 % арттырды, һәм 16869 сумга җитте. Шуны раслап гаилә керемнәренә карап билгеләнә торган социаль ярдәм алучыларнын кимеүен курәбез. Мәсәлән пособие алучылар саны 2017 ел белән чагыштырганда 975 кешегә кимеде.(СЛАЙД)

**Хезмэт базары**

2018 елда районнын хезмэт базарында тотрыклы хэл сакланды. Ел башында 40 эшсез рэсми рэвештэ исэптэ торган булса, ел азагына эшсезлэр саны 35 булды. Эшсезлек кулэме 0,26 % тәшкил итте, әлеге курсәткеч республика районнары арасында иң яхшы курсәткеч.

**<u>Икътисад</u>**

2018 нче елда шактый гына җитди кыенлыклар булуга карамастан, район алдагы еллардагыча эзлекле үсеш юлыннан чигенмәде, гомумән алганда, социаль-икътисадый күрсәткечләребез үзенең уңай динамикасын саклап калды. Район буенча тулаем территориаль продукт күләме 15 млрд 218 млн сум тәшкил итеп узган елгы күрсәткечкә карата 13,6 % үсеш бирде. Тулаем территориаль продуктның структурасына анализ ясаганда - төп өлешен авыл хуҗалыгы-35%, сәнәгать (шул исәптән файдалы казылмалар чыгару һәм эшкәртү сәнәгате) -34%, төзелеш -11, сәүдә – 6% били һәм башкалар.

Икътисад үсешендә районыбызның сәнәгать, төзелеш һәм сәүдә өлкәләренең өлеше зур. 2018елда сатылган барлык продукт күләме 5млрд 353 млн. сум булды, әлеге сан узган ел белән чагыштырганда 2% кубрәк. Сәнәгатьтә җитештерү индексы 2017 нчы ел белән чагыштырганда– 96%тәшкил итте( нефть бәясе кимү белән бәйле). Бюджет системасыннан тыш төп капиталга инвестицияләр куләме 2,5 млр. сум куләмендә кертелде( 2017- 2,492млр.сум).

**<u>Нефть табу</u>** Слайд (таблица)

Җирлектә районның тулаем продуктының үсешенә зур йогынты ясаучы 3 нефть компаниясе – "ОЙЛЭКТ" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, "Татнефть" ачык акционерлык җәмгыятенең "Азнакайнефть" филиалы, "ТатРИТЭКНефть" компанияләре эшли. 2018 нче елда 200 скважинадан барлыгы 514 мең тонна

нефть чыгарылды, бу узган елгы куләмнән 8,5% арткан. Нефть компанияләры район бюджетына саллы гына олеш кертсәләрдә алар белән элемтәне тагын да ныгытып, киләчәктә халыкның социаль-көнкүреш шартларын яхшырту буенча максатчанрак эшләргә кирәк.

Районның эре предприятияләре арасында үзенең саллы күрсәткечләре белән түбәндәге оешмалар аерылып тора:

- 2013 елда эшчәнлеген башлап җибәргән “Әнәк” кошчылык фабрикасы ел саен 26 мең тонна кош ите җитештерә.Биредә 69 кеше хезмәт куя, уртача хезмәт хакы 25000 сум тәшкил итә.

“Агросила-групп” составына кергән Актаныш икмәк кабул итү предприятиясендә 110 кеше хезмәт куя.

Ел саен 70 тонна икмәк кабул итеп, үзенең тегермәнендә 6 мең. тонна он, 6 мең тонна катнаш азык һәм рапс мае җитештерә. 2019 елда он җитештерүне арттыру максатыннан 70,0 млн. сум инвестиция җәлеп итеп, тәүлеккә 45 мең тонна югары сыйфатлы он, шуның эченнән 80% югары сортлы он чыгара торган яңа тегермән төзү күздә тотыла.

- Актаныш агрегат заводы ябык акционерлык җәмгыяте елына 150 млн. сумлык продукция җитештерә. Заводта 108 кеше хезмәт куя. КамАз акционерлык җәмгыяте өчен 7 төрле продукция җитештерә һәм бу елдан аутсорсингка 2 төрле продукция җитештерә башлады.
- Җирлегебездә сөт эшкәртү буенча 3 предприятие эшләп килә.

Элеккеге Киров сөт заводын Белорусия эшмәкәрләре сатып алып, заводка реконструкция үткәреп, үзләренең эшләрен башлап җибәрделәр. Районга 700 млн. сум инвестиция керттеләр, аның күләмен 1,0 млрд. сумга җиткереп, алдагы көннәрдә яңа эшкәртү линияләре куеп, күп төрле сөт продуктлары чыгара башлаячак. Киләчәктә көнгә 200 тонна сөт эшкәртү максат итеп куела.

## АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

**Хөрмәтле депутатлар, чакырылган кунаклар!**

Авыл хуҗалыгы тармагын үстерү, бүгенге көн таләпләренә нигезләнгән яңа технологияләр кертү, аның җитештерүчәнлеген арттыру мөһим бурычларның берсе булып тора.

**1 СЛАЙД** 2018 нче ел кырыс һава шартлары булуга карамастан тулаем алганда район өчен начар булды дип әйтеп булмый. Районыбыз хезмәтчәннәре үзләреннән торган барлык мөмкинлекләрне кулланып эшләргә тырыштылар, кайсыдыр юнәлештә киму күзәтелсә, нигездә барлык төр җитештерү юнәлешләре саклап

калынды. Ел нәтиҗәләре буенча авыл хуҗалыгы продукция җитештерү күләме 5 млрд. 528 млн., ш.э. авыл хуҗалыгы предприятияләре 2 млрд. 836, фермер хуҗалыгы 211, эшкәртү сәнагате 420, шәхси ярдәмчел хуҗалыклары 422, Әнәк кошчылык фабрикасы 1 млрд. 638 млн. сумлык кош ите җитештерде.

**2 СЛАЙД** Әнәк коччылык фабрикасы җитештергән продукөиядән тыш, тулай җитештерүнең бүленешенә күз салсак, ул түбәндәгечә:

- Иң күбе сөт – 39%;
- Игенчелек – 38%;
- Ит - 20%;
- Кош ите - 3%;

**4 СЛАЙД** Җитештергән продукция сатудан хуҗалык һәм фермерларга 2 млд. 639 млн. сум акча кереме булды: хуҗалыклар –2 млд. 484, фермерлар –155 млн сум. Акча кеременең динамикасына караганда, ул сөттән – 40% тәшкил итә.

**5СЛАЙД** Район игенчеләре Республикада иң күләмле тулай җыем 154 мең тонна җыеп, Республикада иң югары күрсәткечкә ирештеләр, гектар көче 32 ц. тәшкил итте. Быел тарихта беренче тапкыр 96 мең тонна икмәк сатуга ирешеп, 880 млн. сум акча кертүне тәэмин иттеләр.Бу әлбәттә игенчеләребезнең һава шартлары кискен килүгә карамастан, технологик таләпләрне үтәп зур хезмәт куюлары нәтиҗәсе дияргә кирәк.

Район буенча 6 мең тонна рапс, горчица, 54 мең чөгендер, 1200 т. бәрәңге, 522 тонна яшелчә җыйнап алынды. Бер шартлы терлеккә 30 ц күләмендә шартлы терлек азыгы әзерләнде.

**6 СЛАЙД** 2018 ел уңышы астына 1 гектарга 55 кг.тәэсир итү көчендә ашлама кертелде. Ел үзенчәлекләрен, технологик алымнарның зур үзгәреш кичерүен исәпкә алганда мондый гына ашлама кертү безнең район өчен түбән. 1 гектарга 85 кг. тәэсир итү көчендә ашлама кертү бурычы куела. Алдагы елда бөртекле һәм күзаклы культураларның тулай җыемы уртача 185 мең тоннага җиткерү безнең өчен еллык күрсәткеч булырга тиеш дип исәплим.

**7 СЛАЙД** Җирдән файдалану нәтиҗәсенә караганда аерма шактый. Ташкын, Наратлы, Нигез хуҗалыгы, Әнәк агрофирмасы 1га сөрем җиренә бөртек бирәмлеге район күрсәткеченнән югары булганда, Эконом, Саф, Алга хуҗалыкларында бу күрсәткеч түбән.

**Өстәмә үз фикерем** ----------------------------------------------------------------
-----------------------------------------------------------------------------------------------
-----

Районда терлекчелек торышы.

**8 СЛАЙД** Район елны 34700 баш мал белән тәгәлләде, 822 башка арттыруга иреште, ш.э. савым сыерлары 1000 башка артып 10258 башка җитте. Хуҗалыклар һәм фермерларның тырышлыгы нәтиҗәсендә район буенча 58 мең тонна сөт җитештерелеп, ул 101% тәшкил итте; мөгезле эре терлек ите – 5409 т., 103%; кош ите – 26150 т., 98 % булды.

**9 СЛАЙД** 2013-2018 елларга күз салганда, сыер баш саннары стабиль үсештә бара. Бүгенгесе көндә мал баш саннары Әнәк, Чишмә агрофирмалары, Таң, Ташкын, Нигез хуҗалыклары күләмле арттырса, Эконом, Чиялек, Алга, Тамыр, Агыйдел,Саф хуҗалыклары уңай динамика бирә алмады.

**10 СЛАЙД** Төп продукция булган сөт үсеше динамикасына күз салсак, шулай ук район буенча үсештә бара. Үсеш % ларда слайдта күренә.

**11 СЛАЙД (МСХ 30 слайд)**

Авыл хуҗалыгы коллегиясендә күрсәтелгәнчә Кукмара, Балтач, Әтнә, һ.б. берничә районның күләмле үсешен күрсәткәндә, район үсешен зур үсеш дип әйтеп булмый, мөмкинлекләрнең зур икәнлеген безгә тагын бер кат күрсәтә.

**12 СЛАЙД** 100 га авыл хуҗалыгы җирләренә район буенча 547 ц сөт җитештерелде. Хуҗалыклар арасында иң югары күрсәткеч 890ц белән Нур Баян исемендәге хуҗалык тора.

**13 СЛАЙД** Ел эчендә ит җитештерү 99% белән тәгәлләнде, Әнәк кошчылык фабрикасы кош утыртуы белән шулай чыга, ә хуҗалыкларга килгәндә мөгезле эре терлек ите 103%, район буенча иң күп ит арттыручы Чишмә, Әнәк агрофирмасы,Саф, Наратлы, Нигез хуҗалыклары 10% югары үсеш бирә алдылар.

**14 СЛАЙД таблица**

Шулай ук, 100 га авыл хуҗалыгы җирләренә ит җитештерүне караганда Нур Баян, Чишмә, Наратлы, Башак хуҗалыклары, Чишмә агрофирмасында район күрсәткеченнән шактый зур булганда, Алга, Саф, Агыйдел, Чиялек, Эконом хуҗалыклары, Әнәк агрофирмасы күрсәткечләре нигездә уйланырга урын калдыра.

**15 СЛАЙД** 2018-2022 елларга районда кабул ителгән программа нигезендә 2019 ел бурычлары тагын да югарырак: мал баш саны – 36665; сыер саны – 10834; сөт – 62 мең тонн; көндәлек савым – 170 тонна; көндәлек үсеш – 750 гр.; ит җитештерү – 5,4 тонн; программа нигезендә 890 млн. сум күләмендә инвестиция җәлеп ителәчәк.

Район терлекчелегендәге үсеш динамикасы бүгенге шартларда безне канәгатьләндерә алмый. Бүгенгесе көндә Кукмара 2019 елга - 300, 2022 елга 500 тонна; Балтач 2019 елга - 250, 2022 елга - 300 тонна; кечкенә генә Әтнә районы 250 тонна сөт үсешенә барганда, безнең өчен 250 тоннага чыгу зур күрсәткеч итеп санамыйм.

Алдынгы районнар зур инвестиция кредитлары алып, заман таләпләренә

Әтнә р-ны Тукай хуҗалыгы 366 млн., Балтач р-ны Смаил хуҗалыгы 50 млн., Кукмара р-ны Вахит хуҗалыгы 180 млн., Восток хуҗалыгы 120 млн. кредит алып эшләгән вакытта районыбыз хуҗалыкларының эшчәнлеген уңай бәяләп булмый.

**16 СЛАЙД** Райондагы уңай хәрәкәтне дә әйтми китә алмыйм: Ташкын хуҗалыгы җитәкчесе Рәүхәт Салихҗан улы 70 яшьтә булуга карамастан, бүгенге көндә 500 башка исәпләнгән робот фермасын куллануга тапшырырга җыена. Бюджеттан 40 млн. робот алуга ярдәм ителсә дә, бүген хуҗалык тарафыннан 110 млн. сумлык капиталь салым үзләштерелде. Шуның өстенә Венгрия Республикасыннан 155 баш, 30 миллионлык нәселле терлек алып кайтты. Бугенгесе кондә хуҗалык кондәлек 9 тонна сот җитештерә, узган елга карата 2,3 кубрәк. Бу үрнәктә эшләрдәй хуҗалыкларыбыз бар, агымдагы елда уңай якка үзгәреш ясарлар дип уйлыйм.

**17 СЛАЙД** Район хуҗалыкларындагы терлек тыгызлыгына караганда да җирнең эффектлы эшләве турында әле уйланырга урын бар: мәсәлән, 100 га сөрем җиренә Әтнә – 33, Балтач – 37 баш булганда, безнең районда уртача 25 баш кына туры килә, Наратлы, Нур Баян, Чишмә, Ташкын хуҗалыклары, Чишмә агрофирмасы район күрсәткеченнән шактый югары булганда, Агыйдел, Саф, Эконом, Чиялек Тамыр хуҗалыклары, Әнәк агрофирмасының тыгызлыгы бик түбән.

Республикада узган авыл хуҗалыгы министрлыгы коллегиясендә ел нәтиҗәләре буенча районыбыз игенчелек тармагында 2 баскычта, терлекчелек 5 баскыч, гомуми нәтиҗәләр буенча 7 баскычта торса, районның узган елга карата 2 баскычка түбәнәю безне бизәми. Ә районның 1 баскычта торырга тулы мөмкинлеге бар.

Районда сакланып килгән матур традицияләребез бар, ай саен 24 нче форма отчет җыелышлары үткәрелә, ай эчендә намуслы хезмәт күрсәткән алдынгы белгечләр, терлекчеләр күләмле генә премияләргә лаек булалар. **(фото 2-3)**

Ел саен хуҗалыклар белән килешүләр төзелә, 2019 елга да бурычлар куелды. Шуның өчен агымдагы елдан һәрбер җитәкче, белгеч үз юнәлешендә үзгәрешләрне тулы сиземләп, заман технологияләрен кыюрак кертеп, зур җаваплылык белән эшләрләр дип уйлыйм.

Җирле бюдҗеттан:

- Хуҗалыкларга 54,5 млн. сум
- Премия 1 млн.сум
- Тана алучыларга 15мең сум

Савым аппараты.

**Өстәмә үз фикерем** ------------------------------------------------------------------
------------------------------------------------------------------------------------------
-----

## Эшмәкәрлек.

Район икътисады үсешенә шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек зур йогынты ясый. Бүгенге көндә Актаныш районында 6 урта, 167 кече предприятие һәм 550 шәхси эшмәкәр теркәлгән. 2018 елда тулаем территориаль продукт эчендә кече бизнес өлеше 23,9 % тәшкил итте, бу курсәткеч 2017 ел белән чагыштырганда артса да, алдагы елдагы курсәткечләрдән ким, ләкин аның уңай яклары да бар, чонки моңа кадәр урта предприятиедә исәпләнгән оешмалар эре оешмаларга әверелеп эшләрен кинәйтеп давам итәләр (МНКТ, Агрегатный завод, 2 Агрофирма һәм башкалар) Җирлекләрне карау нәтиҗәсендә районда кулланылмаган ресурсларның куплегенә инандык, бүген төп байлыгыбыз: җир һәм терлек, шушы юнәлешкә басым ясарга кирәк. Узмәшгуллек белән салым органнарына исәпкә басмыйча гына эш итучеләр, уз хуҗалыгында мал асрап кон курүчеләр шактый. Алар белән эш алып барганда, яңа законнарны кулланып, аларга хокукый статус биргәндә, эш алга китәр дип саныйм.

Республикада беренчеләрдән булып 2011 елда элеккеге ПМК-746 базасында 9 га мәйданда сәнәгать мәйданчыгы ачылып, 6 резидентка җир участоклары бүленеп бирелеп уңышлы гына эшләвен дәвам итә.

2017 елның декабрь азагында Актаныште Республика һәм федераль бюджет ярдәме белән 13,0 га мәйданда яңа сәнәгать паркы төзелеп файдалануга тапшырылды. Хәзерге көндә әлеге паркта 1 резидент үз эшен алып бара – бу “Касыймовский” сөт заводы. Елга 642 млн сумлык продукция җитештерә.

Сәнәгать паркын тулыландырып тулы кочено эшләуне тәэмин итү өчен яңа резидентлар табып, аларның уз эшләрен башлап җибәрү бурычы тора.

Эшмәкәрләрнең мэнфагатьләрен уз вакытында хәл итү максатыннан 2018 елдан эшмәкәрләр Советы эшен башлап җибәрде. Район җитәкчелеге ай саен эшмәкәрләр белән очрашып хәл итәсе мәсъәләләрне, булган яңалыкларны, торле укытулар һәм белгечләр белән очрашулар уткәрә.

-КООПЕРАТИВ тозу.

### Төзелеш

**2018 елда башкарылган төзелеш эшләре**

Отчет чорында төзелеш буенча подряд оешмалары 1млр. 33 млн. сумлык капитал салым үзләштерде. Тозелеш оешмалары арасында ин зур олеш кертуче булып ОАО “Татавтодор” (Минзәлә филиалы)- 262 млн.сум, ООО “ПМК” 117 млн., ООО “Газстройсервис” 105 млн., ООО “Актаныш юллары” – 80,5 млн. сум, ООО “Стройком” 47 млн., ООО “Ремстройдом” 15 млн. санала. Район 34 республика программасының 24 дә катнашты.

**Слайд.** Подряд оешмаларының Актаныш муниципаль районы буенча башкарган эшләре**.**

### Юллар төзелеше.

Районда барлыгы 1022 км озынлыкта автомобиль юллары бар. Шуның эченнән 38 км озынлыкта федераль юллар, асфальто-бетон катламы белән

озынлыгы асфальтланган, бу 74% тәшкил итә. 625 км озынлыкта муниципаль юллар, шуның 153 км асфальтланган, ул 24% тәшкил итә.

Район үзәгендә барлыгы 85 км автомобиль юллары бар шуның 56 км асфальт белән тушәлгән, бу күрсәткеч 65% тәшкил итә.

Районда 87 авыл бар, барлык зур авыл җирлекләре үзәкләре асфальт юл белән тоташтырылган. Алдагы елларда 15 авылны асфальт юл белән тоташтырасы кала.

Район узәге кварталларын төзекләндерү программасында безнең район катнаша алмый, чөнки бу программа хәзерге көндә шәхәрләрдәге кварталларны тозекләндерү өчен генә кулланыла.

## Торак төзелеше.

**Слайд** Еллап торак мәйданнары тапшыру.

2018 елда район буенча барлыгы гомуми мәйданы 14177 кв.м тәшкил иткән 139 йорт тапшырылды, уз көчләре белән гомуми мәйданы 13549 кв.м тәшкил иткән 130 шәхси йорт төзелде. Бугенге кондэ районда торак белән гомуми тээмин ителеш 1 кешегэ 26,8 кв. м., Республика буенча элеге курсәткеч 25,2 кв.м.

Авылда яшәүче гражданнар программасы буенча шулай ук 45 гаилә 40 млн. сум акча алды.

Социаль ипотека программасы буенча район узэгендэ 1 шэхси йорт, Аняк авылында арендага биру программасы буенча 8 шэхси йорт файдалануга тапшырылды.

3 куп балалы гаилэгэ Тыннамас, Тат.Суксы хэм Шэбез авылларында 3 шэхси йорт тозелде.

Дәүләт торак фонды белән тыгыз эшчәнлек 2005 елдан бирле дәвам итә. Шул вакыт арасында 2003 кеше төрле программаларда катнашты. Хазерге көндә 11 йорт төзелеп беткән.

Халыкның торак-көнкүреш шартларын яхшырту тарафыннан район үзәгендә 3 купфатирлы йортларга 10,3 млн. сумлык капиталь ремонт үткәрелде.

## Су һәм җылылык челтәре.

Актаныш районы территориясендәге 87 авылның 73ендә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы эшли. 11 авыл су челтәре белән тәэмин ителмәгән.

(Слайд 2. ) Су челтәре белән тәэмин ителмәгән авыллар

Район буенча су челтәре 346км, шул исәптән 181км канәгатьләнерлек. Калган 165 км өлеше тузган яки тузып бару хәлендә. Суүткәргечләрнең санитар эпидемиологик таләпләргә туры килмәве аларның тузуы белән аңлатыла. (Слайд 3).

Проблемаларны җиңү максатыннан районда күләмле эш алып барыла. 2017 ел дәвамында район буенча 20 км дан артык су челтәре алмаштырылды. Газлаштыру фонды аша Богады һәм Сәфәр авылларында, җирле бюджеттан Әҗәкүл, Күҗәкә, Чуракай, Такталачык авылларында яңа суүткәргечләр төзелде. Су чыганакларын лицензияләү буенча 10 млн. сумнан артык күләмдә эш башкарылды. Җәй ахырына барлык авыл җирлекләрендәге су чыганакларын лицензияле оешмаларга тапшырып бетерү бурычын куйдык.

## Канализация

2018 елны көненә 1700 куб.м кулланылган су уткәрешле канализация чистарту станциясе файдалануга тапшырылды. Хәзерге көндә канализация чистарту королмаларын район балансына кабул итеп Газлаштыру фондына тапшыру бурычы тора.

14.4 км озынлыктагы канализация торбаларына, икенче насос станциясына реконструкция эшләре эшлисе бар.

**- Тозелеш өчен кадрлар әзерләү,**

**- 2019 елга бурычлар,**

**-сыйфат, вакытында тапшыру.**

**СЛАЙД** 2019 елда төзелеш өлкәсендә торган бурычлар

## Финанс-бюджет системасы

**Слайд** Жирле бюджетның тотрыклылыгы район оешма-преприятиеләренең нәтиҗәле эшчәнлегенә бәйле. 2018 елда барлык төр салымнар һәм җыемнарны да исәпкә алып, керемнәр **896** миллион сум булды. Шул исэптән, федераль хэм республика бюджетларына **532** миллион һәм җирле бюджетка **364** миллион сум күләмендә финанс средстволары тупланды. Соңгы 5 елны алганда уңай динамика күзәтелә.

**Слайд** 2018 ел нәтижәләре буенча жирле бюджетта **52** миллион сумлык өстәмә керем барлыкка килде, шул исэптэн авыл жирлеклэре бюджетларында **16** миллион сум, район бюджетында **36** миллион сум.

**Слайд** Җирле бюджетның төп остэмэ керем чыганагы булган физик затларның керемнәренә салым хисап елында 264 млн сум тупланып, район бюджеты керемнәренең 73%ын тәшкил итте.

**Слайд** Салым структурасына килгэндэ районнын топ тармагы - хужалыклар хисап елында барлыгы 62 млн сум салым түләп, 2017 ел белэн чагыштырганда 3% усеш тээмин итте. Жирле бюджетнын 21 процентын билэде.

**Слайд** Шулай ук соңгы елларда Ресурс Холдинг компаниясенә караган физик хэм юридик затлар, "Агросила", «ГранаТ-Стан Транспорт", «МНКТ», "Транснефть – Прикамье (НПС "Белая"), "Сетевая компания", "Газпром трансгаз" җәмгыятьләре салымнарын даими түләп килеп, бюджет үтәлешенә зур этәргеч ясыйлар.

**Слайд** Тозелеш хэм торак-коммуналь хужалыгы тармагы бюджет керемнәренен нибары 4 процентын тэшкил итеп, уртача 115 процент усеш курсәтте.

**Слайд** Җирле бюджет керемнәренең 13 проценты авыл җирлекләре керемнәренә туры килә. Керем тупланышы авыл халкының җир һәм мөлкәт салымын, шулай ук, соңгы елларда җирлек бюджетлары өчен бик мөһим булган, үзара салым акчаларын вакытында түләүдән тора. 2018 елда бу төр кертемнәр җирлекләрнең үз керемнәренең 19 процентын тәшкил итте.

**Слайд** Барлыгы 9 млн сум үзара салым акчалары тупланып, республика бюджетыннан өстәмә 38 млн сум субсидия бүленеп бирелде һәм максатчан үзләштерелде. Хисап елында авыл җирлеге җитәкчеләренең бу юнәлештә нәтиҗәле эш оештыруларын билгеләп үтәргә кирәк. Шулай да планнаштырылган куләмне жыеп бетермәу нәтижәсендә Республика бюджетыннан 3 млн сумга якын акчаны кайтара алмадык.

## Мәгариф

Мәгариф һәрвакыт үсештә, яңарышта. Район мэгариф оешмалары 2030 Стратегиясенә йөз тотып эшләргә тиешлэр, төп максат булып, тормыш алып барырга әзерлекле, телләрне камил белгән, кече яшьтән үк бизнеска тартылган шәхес тәрбияләү.

**Слайд 2** Тиз үзгәрүчән заманда күп кенә һөнәрләр юкка чыга, яңалары барлыкка килә.

Балаларны 2030 елга әзерләү өчен балалар бакчасыннан ук эшне нәтиҗәле итеп оештырырга. Районның өзлексез белем бирү системасы үсеше мәгарифнең төп бурычы булып кала бирә.

**Слайд 3** Бугенге кондэ 41 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшли.

**Слайд 4** Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирүдә алга куелган бурычларны үтәү өчен Федераль дәүләт белем бирә стандартларына нигезләнеп эш оештырыла.

Бу уку елының яңалыгы булып балалар бакчаларында инглиз теле түгәрәкләре эшли башлады.

**Слайд 5** Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының мәктәпкә әзерлеген ачыклау максатыннан мониторинг үткәрелде. Мониторинг биремнәре федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән 5 юнәлешне үз эченә алып төзелде.

**Слайд 6** Районда белем бирү оешмаларының структурасы булдырылды. Башлангыч, төп белем бирү мәктәпләрен тәмамлаганнан соң укучылар өчен белемнәрен үстерү, сәләтләрен ачу өчен сайлау мөмкинлеге зур. Әлеге максаттан укучылар сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат, ресурс үзәк – техникум, кадет-интернат мәктәбендә белем һәм тәрбия ала алалар.

**Слайд 7** Төп белем бирү мәктәпләре эшчәнлеге буенча рейтинг чыгарылды. Мәктәпләрнең укыту, тәрбия эшчәнлеге, төп дәүләт имтиханнары, олипиадалар, һөнәри конкурслар, патриотик тәрбия, класс җитәкчесе эшчәнлеге, ягъни 13 төр буенча нәтиҗәләр ясалды.

Беренче өчлектә - Байсар, Әтәс, Богады мәктәпләре.

Рейтингның кызыл зонасында булган мәктәпләргә (Качкын, Чуракай, Зөбәер, Меңнәр, Югары Яхшый мәктәпләренә) эшчәнлекләрен тамырдан үзгәртәсе бар

**Слайд 8** Урта белем бирү мәктәпләре эшчәнлеге 17 юнәлеш буенча бәяләнде, рейтинг чыгарылды. Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия –республикада инновацион мәгариф учреждениеләре арасында алдынгы урында.

Алдынгы урында Аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле Актанышның икенче мәктәбе. Кадет һәм Татар Суыксуы мәктәпләренә нәтиҗәле эш оештырырга кирәк. 2018 елда бердәм дәүләт имтиханын 96 укучы тапшырды, барлык укучылар да кулларына өлгергәнлек аттестаты алдылар.

**Слайд 9** Рус теле фәне буенча 100 балл җыючы укучыбыз бар. Ул аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле икенче Актаныш урта мәктәбе укучысы Галимова Айзилә, укытучысы Кулиева Рәвия Закирҗан кызы.

**Слайд 10-11** Районда сәләтле балаларны үстерү, аларга белем, тәрбия алу өчен тиешле шартлар тудыру юнәлешендә максатчан эш оештырыла.

Узган уку елында республикада алган призлы урыннарыбыз белән горурланырлык. Гомуми урыннар саны 66. Республикада Олимпиада хәрәкәте буенча Актаныш районы лидерлар рәтендә, шәһәр мәктәпләреннән кала призлы 7 урында. Бу укучыларыбызның һәм укытучыларыбызның тырыш хезмәте нәтиҗәсе.

Бу уку елында да олимпиадаларның республика этабы оешкан төстә үтә. Бүгенге көндә 82 призлы урыныбыз бар. Нәтиҗәләр буенча лидерлыкны Сәләтле

балалар өчен гуманитар гимназия - интернаты яулый – призлы урыннарның 52 се – аларның уңышы. 1 нче, 2 нче Актаныш урта мәктәпләре активлыкларын аттырдылар. Авыл мәктәпләре арасында Пучы, Әтәс, Мари Суксу, Теләкәй мәктәпләренең призлы урыннары бар. Олимпиада бүгенге көндә дә дәвам итә, бу саннар тагын да артыр дип өметләнәбез.

**Слайд 12** 26 нчы декабрьдә Актанышта "Бүләк" белем бирү үзәге ачылды. Әлеге үзәктә укучылар өчен төрле фәнни өйрәнүләр, олимпиадаларга, имтиханнарга әзерлек, укытучылар өчен укулар, тренинглар, мастер-классларүткәрелә.

**Слайд 13** Мәгариф оешмаларында 1238 хезмәткәр эшли. Шуларның 784 җитәкче һәм педагогик хезмәткәр.

Педагогларның уртача яше - 46.

Стажлары 20 елдан күбрәк укытучылар арта бара, яшь педагогларны кайтару мөһим бурыч булып тора. Бигрәк тә математика, физика, информатика, химия, рус, инглиз телләре, башлангыч сыйныф укытучылары белән тәэмин итүдә эшлисе эшләребез бар. Бүгенге көндә педагогик югары уку йортларында 10 укучының максатчан белем алуы уңай күренеш. Ләкин бу саннарны артыру безнең бурыч булып тора.

**Слайд 14** Шул максаттан чыгып мәгариф хезмәткәрләре арасында һөнәри бәйге игълан ителде. Башлангыч, рус, инглиз теле, математика, тарих укытучылары белән бәйгеләр үткәрелде. Башлангыч укытучыларының һөнәр компетентлыгын арттыру максатыннан Мәгарифне үстерү институты, Казан федераль универститеты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты белән укулар үткәрелде, бүгенге көндә дә хезмәттәшлек дәвам итә.

**Слайд 15** Районда 27 педагог грантларга ия булдылар.

**Слайд 16** Район күләмендә "Уңышлы мәктәп" проекты үз эшен дәвам итә. Мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре һәм балалар бакчалары мөдирләре белән Казан (Идел буе) Федераль университеты һәм Мәскәү шәһәренең фәнни-эзләнү "Югары икътисад мәктәбе" белгечләре укулар үткәрәләр.

**Слайд 17-18-19** Заман таләбе - балаларны техник иҗатка тарту. Бездә техник иҗат белән кызыксынучы балалар күп. Бу эшне оештыру өчен районда әзерлекле кадрлар, техник базаны булдыру кирэк. Шул максаттан Мэгариф хэм фэн министрлыгы тарафыннан уткэрелгэн "Балалар сәнәгать робототехникасының терәк мәйданчыгы булдыру" конкурсында "Балалар ижат узэге" 600 мең сумлык грант отып, робот техникасы җиһазлары комплекты кайтарылды.

**Слайд 20**

Мәгариф системасына бүгенге көндә зур бурычлар куела:

- мәгариф системасын югары компетенцияле математика, рус теле, физика, инглиз теле, информатика укытучылары белән тәэмин итү;

• балалар бакчасы, башлангыч, урта сыйныфларда, урта махсус уку йортларында балаларга өзлексез нигезле белем һәм тәрбия бирү;

• 3 телне (татар теле, рус теле, инглиз теле) камил белгән укучылар тәрбияләү;

• укучыларда цифрлы дөньяда яшәү күнекмәләрен формалаштыру.

• мәктәп яшеннән укучыларда эшмәкәрлеккә кызыксыну уяту, “Эшмәкәрлек фабрикасы” на катнашу.

## Мәдәният

Актаныш бай мәдәниятле төбәк, аның йөзе, үз кыйбласы бар. Мәдәниятнең төп бурычлары – телебезне, динебезне, милли үз аңыбызны саклап калу һәм өйрәнү, киләчәк буыннарга тапшыру. 2018 елнын төп темасы булып “Кече Ватан” булды . Иң беренчеләрдлән булып “Халкым хәзинәсе” - авылдашлар жыены фестиваль-конкурсын атап китәсе килә. Һәр җирлек Фестиваль аша халкыбызның, авылларыбызның тарихын, ижатын, гөреф –гадәтләрен тирәнрәк өйрәнде, легендар шәхесләрне туган якка тарту, тугандашлык җепләрен ныгытып Татарстан, Башкортостан республикасында урнашкан адаш авыллар белән дуслык, иҗат күперләре төзү юнәлешендә күләмле эш башкарды. Җирлектә һәм читтә яшәүче районандашларыбызның “Халкым хәзинәсе” фестиваленә югары бәя бирде. 2019 елда да “Кече ватан” темасын “Үткәннәрдән киләчәккә таба” фестиваль конкурсы белән дәвам итүне планлаштырабыз. Конкурс кысаларында иң беренчеләрдән булып җирдә, туган туфракта хезмәт куйган шәхесләребезне; авыл үсешенә риясыз өлешен керткән җитәкчеләрне данлыячакбыз.

Дистә еллар буена дәвам иткән тагын бер зур традициябез бар –ул театр.Һәр авылда үзешчәннәр театры эшләп килә, шулар арсыннан 9 халык театры исмен йөрткән коллективларыбыз бар. 2018 елда театр коллективлары смотрында татар, башкорт драматургларының 50 әсәре сәхнәләштерелде. Шунысы сөендерә коллективларыбыз профессиональ артистлар гына уйный алырлыклык әсәрләргә курыкмыйча алыналар һәм үз югарылыгында башкарып та чыгалар.

Актанышыбызда 98 процент татарлар яши, безнең максат саф мәдәниятеле, телен саклаган татар милләтенең үзәген булдыру. Башка төбәкләр безгә карап “Мин дә татар “ – дип горурланырга тиешләр. Районыбызда югарыда әйтелгән

а

л

м

а

к

“Актаныш гармуннары” фестивале яңа буын үзебезнең районда һәм респбуликада яңа буын гармунчылар тәрбияләнүенә этәргеч ясарга тиеш.

Милләтебезне, татар моңын ятим итеп мәшһүр җырчыларыбыз Әлфия Авзалова һәм Илһам Шакиров бакыйлыкка күчеп тарихта калдылар. Татар милләтенә риясыз хезмәт итүче моң ияләрен барлау, үстерү максатыннан, 2018 елның җәендә Актанышыбызда  Әлфия Авзалова исемендәге халык ара конкурс кысаларында 1 нче регион ара җыр һәм бию фестивале үткәрелде. Фестивальда 100 артык  конкурсант катнашып вокал һәм бию номинаөияләрендә көч сынаштылар. Бездә башлангыч алып Әлфия Авзалова исемендәге фестиваль халык ара дәрәҗәсенә җитеп бөтендөнья куләменә чыкты.

Ел дәвамында куйган хезмәтләреннән чыгып иң яхшы мәдәният йортлары дип Иске Кормаш, Киров, Иске Байсар, Татар Суыксу Сәфәр, Кәзкәй коллективларын танылды.

Актанышыбызның зур байлыгы -  Агыйдел җыр һәм бию ансамбле. Үткән гасырның алтмышынчы елларында нигез салынган ансамбль бүгенге көндә дәүләт статусын йөртә. Ансамбль профессиональ дәрәҗәдә    районыбызга гына түгел, республика  мәдәниятенә дә зур йогынты ясады. Ансамбль алга таба да тулы куәткә район һәм республикага хезмәт итәргә тиеш. Актаныш сәнгать мәктәбен тәмамлаган укучыларны, райондагы талантлы яшьләрне иҗади яктан үстерүнең дәвамчанлыгын тәэмин итүен булдыруын да кирәк дип саныйбыз.

2019 елның иң зур  мәдәни чаралары булып апрель аенда Казан шәхәренең Г.Камал ис. Татар дәүләт драма театрында  узачак районыбызның халык театрларының иң  оста артистларыннан тупланган  төркемнең тарихи масштаблы спектакле  (Нурихан Фаттах “Итиль суы ака торур”), июндә регионара “Ык буе ” сабантуен үткәреп  Актанышыбызны республиканың  саф татар үзәге итеп исбатларга тиешбез.

### Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм.

2018 елдан  Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы рәсми рәвештә бүленеп яшьләр эшләре министрлыгы һәм спорт министрлыгы булып эшли башлады.

Шулай да, республикабызның  күп кенә районнарында бу бүленеш булдырылмады. Бүгенгесе көндә яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге менә шундый структура буенча эш башкара. Бүлеккә килгәндә, нәтиҗәлерәк эш алып барыр өчен кадрлар җитмәү, яшьләр үзәге, яшүсмерләр клубы булдырылмаган. Элекке вакытларда районныбызның һәрбер авыл җирлегендә  яшьләр белән эшләүче белгечләр булса хәзерге көндә финанс яктан проблемалар булу сәбәпле

бу эш туктатылды. Яшьләр эшләрен районыбызда,авылларда торгызу,нәтиҗәле эш булдыру өчен яңа белгечләр билгеләү бурыч булып тора.

Районда спорт һәм физкультура өлкәсендә барлыгы ике учреждение халыкка хезмәт курсәтә. Матди техник базага килгәндә, районыбызда спорт корылмалары эшләп килә: "Иман" спорт комплексы, "Лачын" боз спорт сарае, "Батыр" спорт сарае, "Дулкын" йөзү бассейны, "Буләк" чаңгы базасы, республика программалары нигезендә төзелгән Үзәк стадион, волейбол-баскетбол,мини-футбол мәйданчыклары.

Шул ук программалар ярдәмендә 2018 елда Актанышбаш авыл жирлегендә мини футбол майданчыгы, 57 бистәдә модульле чаңгы базасы тозелеп файдалануга тапшырылды.

Киләчәктә район халкының физик әзерлеген тагы да үстерү өчен авыл җирлекләрендә спорт корылмалары,мәйданчыклары,Пучы авыл җирлегендә барлык шартлары да тудырылган спорт корылмасы, районыбыз үзәгендә тау-чаңгысы комплексы булдыру күздә тотыла.

Слайд 2018 нче елда ирешелгән уңышлар.

2019 елның 13-15 февральдә район үзәгендә беренче тапкыр уздырылган М.Җәлил истәлегенә багышланган республикакүләм корәш ярышында райондашларыбыз Искәндәр Муртазин – 1, Нургалиев Раббани-3,Гәбдрәшитов Азат – 3,Сираев Раиль- 3 яуладылар. Актаныш җыелма командасы 2 урын яулады.15-17 февральдә үткән Россиякүләм ярышта Татарстан республикасы составында катнашып райондашларыбыз Азат Гәбдрәшитов,Муртазин Искәндәр,Нургалиев Раббани чемпион калып,спорт мастерлыгы дәрәҗәсен үтәделәр.

Районда ел дәвамында оешма- предприятие, мәгариф учрежденияләре,авыл җирлекләре арасында кышкы,җәйге спартакиадалар бик актив рәвештә уздырыла. Кыш айларында оешма- предприятие, авыл җирлекләре арасында хоккей ярышлары, җәй коннәрендә 3 ай дәвамында үзәк стадионда футбол уеннары уздырылды.

2018 елда республика районнары арасында гомуми рейтинг нәтиҗәсендә безнең район 10нче баскычта тора.

2018 елда спорт мәктәплэренә 2 яшь югары белемле тренерлар кайтты. Лачын боз спорт мэктэбенэ чангы спорты буенча тренер Рәшитов Илгиз,балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбенә жинел атлетика буенча Бахтиева Нәзилә. Бүгенге көндә Казан Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясендә 7 тудент белем ала. Яшь белгечләребезне укуларын тәмамлаганнан соң эш белән тәэмин итү бурыч булып тора.

Районыбызда күпкенә спорт төрләре белән шогельләнергә, шартлар тудырылса да фигуралы шуу,бокс, ирекле көрәш кебек төрләр белән эшләүче белгечләребез юк.

Агымдагы елда апрель аенда ТР беренче президенты М.Ш.Шәймиев призына 20нче тапкыр көрәш турниры уздыралачак.

2-9 июльдә беренче тапкыр районыбызда республикакүләм “Авыл яшьләре” спорт уеннарын уздыру планнаштырала. Бу ярышларда республиканың район,шәһәрләреннән командалар килүе көтелә.

## СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ.

Актаныш районында медицина ярдәме күрсәтү үзәк район хастаханәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла, анда тәүлек буе эшли торган 101 койка һәм 36 көндезге бүлек эшли. Амбулатор ярдәм поликлиника аша башкарыла.

Районда Пучы участок хастаханәсе, Байсар, Такталачык, Суыксу табиблык амбулаторияларе эшли. Авылларда 61 фельдшер-акушерлык пункты ярдәмгә килә.

"Актаныш район узәк хастәханәсе» сәламәтлек саклау оешмаларының гомуми рейтингында 45 муниципаль оешма арасында 15 урынны алып тора, 2017 елда 25нче, 2016 елны 45нче урында булган.

2018 елга план буенча 4486 кеше диспансеризация үтәргә тиешле булып, 4720 кеше каралды, Еллык планнын утэлеше 105,2 %.

Диспансеризация нәтиҗәләре буенча 606 кешедә авыру ачыкланды.

2 нче этапта –690 кеше, 14,61 %

Барлыгы 2018 елда 98 онкологик авыру ачыкланды. Үткәрелгән диспансерлаштыру нәтиҗәләре буенча онкоавыруларына шикнең 32 очрагы ачыкланган, алар тикшерелеп, исәпкә куелган. I-II стадияләрдә ачыкланган онкология авырулары өлеше 51 очрак, 52,0% тәшкил итте.

Район сәламәтлек саклау тарихында беренче тапкыр-үзәк район хастаханәсе шартларында органнар һәм тукымалар гистологик тикшеренүләрне уздыру оештырылды, бу исә авыруларны төгәл һәм сыйфатлы диагностикалауга ярдәм итәчәк.

Районның сәламәтлек саклау учреждениеләрендә 425 кеше эшли, шуларның 51е-табиблар, уртача медицина персоналы-237 кеше, кече медицина персоналы-10 кеше, башкалар-125 кеше. 2012 елдан “Земский доктор” программасы буенча районга 36 табиб эшкә килде, шуның 14 кире китте, 7се декрет ялында, 15 табиб бугенге кондә халыкка хемәт курсәтә. Актаныш узәк хастахәнәсенең кадрлар белән тәэмин ителеше 79%, шуның эчендә стационар 88%, поликлиника 77%.

Кадрлар белән тәэмин итү максаты белән 2018 елда район үзәк хастаханәсенә: 1 офтальмолог, 1 педиатр, 1 участок терапевты, 1 стоматолог эшкә кабул ителде. Түбәндәге белгечләр җитми: оталарингголог, уролог, невролог, хирург, балалар хирургы, УЗИ табибы, ашыгыч ярдәм табибы, эндоскопист, ренгенолог. Узәк хастаханәне якын арада житмәуче һәм югары квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү бурычы тора.

Шулар белән бер рәттән узәк хастахәнә дә УЗИ һәм гинекология белгечләре булуга карамастан, район халкының бер олеше бу белгечләргә курше Илеш районы Югары Яркәй "Медсервис" клиникасына йөриләр. Аларның аңлатуы буенча клиникада тикшеруне комплекслы уткәрәләр һәм 1 сәгәтъ эчендә анализларда эзер була, УЗИ дә утәсең, врачы да карап нәтиҗәсен һәм киңәшләрен язып бирә. Шуңа курә киләчәктә район халкына, узебезнең хастахәнәдә белгечләрнең тиешле югарылыкта һәм нштиҗәле каравын оештыру таләп итеlә. Бугенге кондә бушлай УЗИ утәр очен 2-3 ай алдан язылу мохим, бу да халыкның ризасызлыгын тудыра.

2018 елда поликлиникага һәм хатын-кызлар консультациясенә 902,2 млн.сумлык капиталь ремонт уткәрелде.

Әҗәкүл авылында гомуми мәйданы 62.5 кв.м. булган модульле фельдшер-акушерлык пункты төзелде. Төзелгән фельдшер-акушерлык пункты тулысынча медицина җиһазлары һәм мебель белән җиһазландырылган. Сожгы 7 елда районда 10 модулле ФАП тозелеп файдалануга тапшырылды, тагын 4 Фап тозисе бар.

**2019 елга бурычлар**

- Актаныш муниципаль районы халкына медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту һәм үтемлелеген тәэмин итү;
- Актаныш муниципаль районы халкын, шул исәптән Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм аларга тиңләштерелгән затларны диспансерлаштыру үткәрү;
- балигъ булмаган балаларга профилактик тикшерү үткәрү;
- үлүчеләр саны, шул исәптән эшкә яраклы яшьтәге халык үлеменең кимүе;
- сабыйлык үлеме санының кимүе (вакытында Перинаталь диагностика, перинаталь үзәк белән хезмәттәшлек итү);
- инвалидлыкка беренчел чыгу очракларын киметү;
- башлап җибәрелгән авырулар формалары, шул исәптән онкология санының кимүе;

**ХОКУК САКЛАУ**

2018 ел нәтиҗәләре буенча эчке эшләр органнары эшчәнлеге һәм аларның эш нәтиҗәләрен комплексы бәяләү буенча 3 категориясенә кергән. Татарстан

Республикасының 21 район бүлеге арасында Россия эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге 10 нчы урында тора, бу шактый уңай нәтиҗә, 2017 елда 21 урында булган.

Районда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләсе актуаль булып кала.

2018 елның 12 аенда Актаныш районы территориясендә 34 юл-транспорт һәлакәте булды, алар арасында 8 кеше һәлак һәм 39 кеше тән җәрәхәтләре алды. Юл-транспорт һәлакәтләре саны 13.3 %, һәлак булучылар саны 3 кешегә, тән җәрәхәтләре алучылар саны 10 кешегә артты.

Ялган аракы сатуны ачыклау һәм чикләү остендә нәтиҗәле эш алып баруны алдагы елга бурыч итеп кую максат.

Участок полиция инпекторларын кадрлар белән тәэмин иту бугенге кондә проблема булып кала(2 вакансия, текучесть кадров).

## Авыл җирлекләре эшчәнлеге

Авыл җирлекләренең төп максаты – җирле үзидарәнең эшчәнлеген 131 нче санлы Федераль һәм 45 санлы Татарстан Республикасы законнарына нигезләнеп оештыру. Җирлекләрдә башкарылган эшләр бихисап булса да, авыл проблемалары җитәрлек әле. Халыкны авылда яшәтү, киләчәге булсын өчен аның су, юл һәм башка көнүзәк проблемаларын чишү зарур.

Авылдагы проблемаларны хәл итүдә иң зур ярдәм - үзара салым. Хисап елында 26 авыл җирлегендә үзара салым акчасын җыю буенча референдумнар үткәрелде. Акчалар халыктан үз вакытында җыеп алынып республика программасы нигезендә дүрткә тапкырланып күләмле генә сумманы тәшкил итте.

Җыелган акчалар авыл җирлекләрендә суүткәргечләрне яңарту, урам утларын көйләү, һәйкәлләрне, зиратларны, авыл урамнарын төзекләндерүгә тотылды.

Ел нәтиҗәләреннән чыгып авыл җирлекләре арасында 11 күрсәткеч буенча анализ ясалып урыннар чыгарылды. Әтәс, Күҗәкә, Такталачык, Түке, Иске Сәфәр, Киров авыл җирлекләренә яхшы эш оештыруларын искә алып дипломнар тапшырылды. Иске Богады, Мәсәде, Чуракай авыл җирлекләренең эшчәнлеген активлаштыру кирәк була.

9750 шәхси хуҗалыкларда барлыгы 11145 могезле эре терлек асрала, шул хисаптан 4621 савым сыеры. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүдә дә шәхси хуҗалыкларның өлеше бихисап. Ел башында мал баш санынын арттыру буенча авыл башлыкларына бурыч куелган иде, ел нәтиҗәләре буенча иң куп мал баш санын арттыручы 4 авыл җирлеге башлыгына 100 мең сумлык сертификатлар

тапшырылды. Шәхси хуҗалыкларда терлек баш санын арттыру юнәлешендә район бюджетыннан 18 шәхси хуҗалык тана алуга 435 мең сумлык ярдәм алды.

Быел район җитәкчелеге командасы белән авыл халкының һәм кече хуҗалыкларның активлыгын арттыру максатыннан һәр җирлектә купләп терлек асраучы һәм терлек асрарга теләге булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларда булып, халыкның яшәеше белән якыннанрак танышу форматында үтте. Авыл хуҗалыгы идарәсе һәм икътисад бүлеге җитәкчеләре халыкны республикада уңышлы эшләп килүче программалардагы үзгәрешләр белән якыннан таныштырды. Халыктан кергән сорауларга җаваплар бирелде.

Слайд 2019 елда дәүләт программаларында катнашып ярдәм алуга дәгъва белдерүчеләр

**Хөрмәтле депутатлар!**

**Хөрмәтле утырышта катнашучылар**!

2019 ел да сәяси истәлекле, тарихи вакыйгаларга бай ел булыр кебек күренә. Зур сәяси, республика тормышында бик мөһим урын алган вакыйга булып сентябрь аенда узачак Татарстан Республикасы Югары Советы депутатларын сайлау булып тора. Республиканың яңа составта парламенты сайланачак.

Бу сайлауларга әзерлек эшен хәзерге көннән үк башлап, ныклы әзерлек белән үткәрү безнең төп бурычларның берсе булып кала. Барлык сайлаучыларның да сайлауларда актив катнашырлык итеп эш оештырырга кирәк булачак.

Гомумән 2019 елда районда яшәүче халыкның тулаем һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итү, тормыш-көнкүрешләрен яхшырту, җирлекләрдә социаль мәсьәләләрне хәл итү, салым базасын ныгыту, булган табигый байлыкларны саклау, яшәешебезнең төп бурычлары булып кала.

Бер отчет докладында гына районда эшләнгән эшләрне, алда торган бурычларны ачып та бетереп булмый, шуңа күрә чыгыш ясаучылар докладны тулыландырырлар һәм киләчәктә район Советы, аның Башкарма комитеты эшчәнлеген яхшырту буенча эшлекле тәкъдимнәрен әйтерләр дип ышынам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!